ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№_2_ от «__10__»___01_____2018 г.

2018 елга Мамадыш муниципаль районында туризм- туган якны өйрәнү, экология – биология, хәрби – патриотик , социаль- педагогик, социаль – икътисадый, табигый – фәнни, техник һәм культурология юнәлешләрендәге һәм күп профильле балаларга өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында

"Россия Федерациясендә мәгариф турында" 2012 елның 29 декабрендәге 273 – ФЗ санлы Федераль законның 99 маддәсе, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131- ФЗ Федераль законның 15 маддәсенең 1 кисәге, 11 пункты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасының туризм- туган якны өйрәнү , экология – биология, хәрби- патриотик, социаль- педагогик, социаль – икътисадый, табигый – фәнни, техник һәм культурология юнәлешләрендәге балаларга өстәмә белем бирү мәгариф учреждениеләрен һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күп профильле мәгариф учреждениеләрен финанслау нормативларын исәпләү турындагы нигезләмәне раслау турында" 2009 елның 31 декабрендәге 939 нчы санлы карары, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты турындагы Нигезләмәгә таянып, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты

к а р а р б и р ә:

1. 2018 елга расларга:

- 2018 елга Мамадыш муниципаль районында туризм- туган якны өйрәнү, экология – биология, хәрби – патриотик , социаль- педагогик, социаль – икътисадый, табигый – фәнни, техник һәм культурология юнәлешләрендәге һәм күп профильле балаларга өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәткүрсәтүгә норматив чыгымнарны 1 №лы кушымтада каралганча;

- 2018 елга Мамадыш муниципаль районында туризм- туган якны өйрәнү, экология – биология, хәрби – патриотик , социаль- педагогик, социаль – икътисадый, табигый – фәнни, техник һәм культурология юнәлешләрендәге һәм күп профильле балаларга өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарга төзәтмә кертү коэффициентын 0,5 күләмендә.

2. Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының финанс- бюджет палатасына(Сергеев А.М.) түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

- балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларын әлеге карарның 1 пунктында каралган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнарына туры китереп финанслауны;

- гамәлдә булул вакыты дәвамында әлеге карарның 1 пунктында каралган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларын әлеге карарның 1 пунктында каралган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнарын, хезмәт турындагы законнарда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптәгамәлгә ашырыла торган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмалары хезмәткәрләрнең хезмәт хакын индексацияләү белән бер үк вакытта яңадан карап чыгуны.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм 2018 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә тарала.

4. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы башкарма комитетының матбугат һәм массакүләм чаралары белән хезмәттәшлек секторына әлеге карарны интернет мәгълүмати - коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасының хокукый рәсми порталында һәм Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары В.И.Никитинга йөкләргә.

Җитәкче вазифаларын
башкаручы И.М. Дәрҗеманов